ВЕСТИ ИЗ БУГУРУСЛАНА

# И ТУГАН ТЕЛ, И МАТУР ТЕЛ

Туган җирен һәрвакыт ихлас яраткән, халыкның үткәненә беркайчан да битараф булмаган, гасырлар килсә дә кыйммәтен — асылын җуймаган, гореф — гадәтләренә, әдәбиятына, диненә ихтирам белән караган кеше генә туган телен чиксез кадерли, аны бөтен күңеле белән яратып өйрәнә, үзенең татар икәнен бар йөрәге белән сизеп яши.

"Тел — халыкның горурлыгы,
Яшәве һәм барлыгы.
Чиксез кыйммәтле хәзинә,
Аның рухи байлыгы." –

шушы шигъри юлларын гади укытучы Рафаэль Сафин җиткерде.

Туган телнең үзен кадерләү, олылау бәйрәме дә бар — 21 февраль, Халыкара туган тел көне.

Ел саен 6нчы санлы китапханә мәктәпләрдә шуңа багышланган чаралар үткәрә, быел да бәйрәм уңаеннан татар телен, тарихын өйрәнү түгәрәге җитәкчесе Марат Галимҗан улы Закиров белән берләшеп, 2нче санлы мәктәптә бәйрәм уздырдык.

Күз салыйк шунда.

Гасыр башында халык әдәбиятын, тел өйрәнүне юлга салуда бөек шагыйрь Габдулла Тукайның роле искиткеч зур булды. "Бездә әдәбият бар һәм дә — бай әдәбият," — дигән шагыйрь.

Әйе, Габдулла Тукайның туган телебезнең сихри моңнарын бар нечкәлекләре белән безгә җдиткерде шагыйрь. "Туган тел" шигырен (халык аны яратып, моңга салган) татар халкы үзе теленә гимн итеп сайлады.

Туган телебез — татар теле. Ул бик борынгы һәм бик бай телләрнең берсе. ЮНЕСКО тарафыннан халыкара араланың теле дип саналган үндүрт телләрнең берсе-татар теле. Шуның өчен без туган телебез белән чиксез горурланабыз.

Бүгенге көндә татарлар өчен күп кенә газеты — журналлар чыга, радио, телетапшырулар алып барыла. Без барыбызда "Яңа Гасыр" тапшыруларын бик яратып, үз итеп карыйбыз. Бу иараллар телне, динне, гөреф — гадәтләрне онытырга юл куймаган. Безнең китапханәдә дә бу изге эштә актив катнаша. ТИҮ "Туган тел" тарафыннан юнәлтелгән газета — журналлар күптән инде үз укучыларын тапты.

Туган телне бары тик татар халкы гына ана теле дип әйтә. Чөнки беренче сүзләрне безгә кадерле әниләбез өйрәткән.

Ә татар теле өйрәнүгә укучылар нинди тел биеклыкларына ия икән. Шуны белү өчен викторинолар, уеннар,ярышллар (телне ни дәрәҗәдә белуләрен ачыклау өчен) бик теләп үткәрдек. Шуны әйтәсе килә: телне өйрәнү дә шактый кыенлыклар бар. Бик теләп, бик яратып телеңне — шул чакта гына нәтиҗә була. Галиә дә зур өлешен кертә баланың телне белүдә — белдәүдә. Шуңа күрә күп көч салырга кирәк барыбызга да.

"Чатнатып" татар телендә шигырь сөйләсә, өздереп үз телендә җыр башкарса, биесә, аралашканда да татар телен артка куймас балалар! Әгәр дә шулай милли киемнәр киеп сәхнәдән чыгыш ясасалар — бер ата — ана, әби — бабай да битараф калмаслар иде. Тырышып карыйк, җәмәгать, ә?

Бу язмамны шагыйрь Гамил Афзал сүзләре белән тәмамлау теләге туды:

"Җырларның да иң татлысы
синдә генә,
Уйларың да иң яктысы
синдә генә.
Туган илнең, туган телнең
матурлыгы
Якты илһам бирми икән
кемгә генә".

**Гөлфия ЛАТЫЙПОВА,**
**китапханәче,**
**Богырыслан шәһәре.**



# ГӨРЛӘШЕП ЯШИК ӘЛЕ!

Безнең Бугырыслан шәһәрендә менә 9 ел инде "Сүнмәс дәрт" исемле үзешчән сәнгать түгәрәге эшли.Башлап җибәргәндә без бары 7 кеше идек, хәзер 22! Башта ветераннар сәнгать пүгәрәге генә булын оешкан идек, хәзер коллективта яшьләр дә, балалар да бар.

"Ни кирәк бу картларга?" — дип әйтүчеләр дә бардыр. Без чын патриотлар. Сүнеп барган татар культурасын, сәнгатен, әдәбиятын, татарның гореф — гадәтләрен күтәрергә хыялланабыз. Шуңа күрә яшьләрне дә үз янябызга тарттык, без картаябыз.

Булган бит шундый көннәр, Богырысланның "Тукай" клубы гөрләп торган! Анда Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану", Галиәскәр камалның "Банкрот" исемле һ.б. классик драмалар куелган! Хәзер анда клуб мөдире булып яшь, талантлы специалист Румия Хамитова эшли. Эш җайга салыныр дип өметләнәбез. "Сүнмәс дәрт" исеменнән зур рәхмәт белдерәбез:

- 8че библиотека коллективы безне ачык чырай белән каршы ала, ярдәм итә. Библиотека мөдире Миргалеева С.Я. безгә караоке җырларга мөмкинчелек тудырды: телевизор, DVD, микрофон булдырды. Без, башлыча, 8че библиотекада, сирәк кенә "Тукай" клубында бәйрәмнәргә (Яңа ел, Ил саклаучылар көне, Халыкара хатын — кызлар көне, халыкара көне(1 май), җиңү көне, картлар көне һ.б.), язучыларга, шагыйрьләргә, дини бәйрәмнәргә багышланган әдиби һәм тематик кичәләр, китап укучыларне конференцияләре, концертлар, спектакльләр куябыз. Кварталга бер җыелып, киләсе кварталга эш планы төзибез, үткән кварталда туган "Сүнмәс дәрт" агъзаларын туган көннәре белән котлыйбыз.

"Җырлыйк әле" дигән музыкаль конкурс 8че библиотекада күңелле генә үтте. 3 команда (9 кеше) ярышты. Ярышның беренче берегендә Гарифуллина Ф., Шакурова К., Шубина Н. җиңде, ә бу өч җиңүче арасыннан халык җиңүче итеп Гарифуллина Фәһимәне танытты.

Муса Җәлилгә багышланган "Улемне җиңгән җырлар" исемле әдәби кичә һәм концерт 3 сәгатькә сузылды. Залда утыручыларның берсе дә кичә бетмичә кайтын китмәде. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты һәм батырлыгы турындагы доклад барганда М.Җәлилнең 8 шигере укылды. Концерт бүлегендә Җәлил шигеренә язылган җырлар ("Җырларым", "Сагыну", "Хат ташучы" поэмасыннан "Асиясе, Вәсиләсе"), "Ишек төбендә" шигереннән эшкәртелгән сценка. "Муса Җәлил геройлары бездә кунакта" дигән викторина гади викторина түгел иде. Мәсәлән: "Менә бу алтын чәчле гүзәл кыз (Барби) шагыйрьнең кайсы музыкаль әсәреннән?" ("Алтын чәч". Либретто). "Бу сандугач кайсы әсәрдән? Нинди батырлык эшләгән?"("Сандугач һәм чишмә". Баллада. Ул немецлар агулан киткән чишмәдән су эчеп үлә. Совет солдатын үлемнән коткара). Халык бу кичәдә шагыйрьнең 29 әсәре турында мәгълүмат алды. Без моңа кәнәгать.

Олыларның күңелен күреп дини кичәләр дә уздырабыз. Ф. Яхиннның "Пәйгамбәрләр, Фәрештәләр", Ахирәт" исемле китабы буенча ике конференция үткәрдек. Беренчесендә сүз пәйгамбәрләр турында барды: Адәм Идрис, Нух, Ибраһим, Исмәгыйль, Муса, Гайса, Мөхәммәт сәлаллаһи галәйһиссәлам.

Икенче очрашуда Ахирәт турында сөйләдек. Гүргә керү, соал алу, гүрдә яту, күңел дәртәре, чарше күләгәсе, сират күперен кичү, оҗмах, ташуг турында сөйләдек.

Бер очрашуда корбан гаетенең каян килеп чыгуы турында сүз барды.

Бер танкыр үзебезнең көчебез б-н авыз ачтырдык.

Киләчәктә дә тырышын эшләргә исәп бар.

Бу көннәрдә Ил саклаучылар көненә әзерләнәбез. 10 ир — атны бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Биографияләре чагылыр. Хәләл җәфәтләре үзләрен бәләкләр.

Аннан аларга багышланган зур концерт булачак.

8 март бәйрәмен дә танталы рәвештә үткәрергә исән.

**Флюра МИЛЯЕВА.**
**Богырыслан шәһәре.**

КНИЖНЫЕ НОВИНКИ

# О Бугуруслане на татарском языке

**В третьем и четвертом номерах нашей газеты, мы уже рассказывали об этой книге. Сегодня, по просьбе читателей и с согласия автора М.Г.Закирова, публикуем очередной отрывок из книги о Бугуруслане.**

219-нчы гасырның азагында һәм 20-нче гасырның башында Богырыслан сәүдәгәрчеләр шәһәренә Идел буе тирәсеннән татарлар күчеп килгәннәр. Алар күбесе прказчиклар булып эшләгәннәр, кайсысы кондитер эшләнмәләре әзерләп, үзләренең кеч-кенә кибетләрендә сатканнар. Коръән кушуы буенча, ел саен мәчеткә, ятимнәргә диеп зәкят биргәннәр. Шәһәрдә ул вакытта ике мәчет булган. Берсе — Мещанская урамында, икенчесе — Нацменская урамында. Халык аларны түбәләренең буяуы өчен "кызыл" һәм "ак" мәчетләр дип йөрткәннәр.

Әлек Богырыслан провинция шәһәре булган. Кинәле яры буенда ике дистәгә якын һөнәрханәләр булган. Аларны халык "завод" дип атаган, андагы урам да "Заводская" дип аталган. Ул "завод"лар Кинәле буенча тезелеп киткән бәләкәй генә бүрәнәдән корган өйләрдә төпләнгәннәр. Берсендә мал — туар соякләреннән агач җилеме кайнатканнар, икенчесендә май эреткәннәр, өченчесендә — балавыз ясаганнар, берничәсе тимерче алачыгы булып торган.

Җилем чыгара торган "заводта" өч кеше эшләгән. Бәләкәй генә җир идәнле өй әченең уртасында зур казанга эшчеләр сөякләр тутырганнар, казан астына ут ягып, аларны көннәр буе кайнатканнар. Ишексез, тәрәзәсез өй төтен белән тулган. Эшчеләр үрмәләп кереп, учакка утын өстәгәннәр һәм төтенгә тончыга — тончыга тизрәк һавага чыгып сулыш алырга ашыкканнар.

Тимерчеләрне алсак, шәһәрдә бик оста һәм тырыш Кобылин исемле тимерче яшәгән. Тирә якта халык үзләренең эшләре буенча аңа агылганнар. Тимерче баеп киткән, үзенә кибет ачып тимер — савыт сатып сәүдәгәргә әйләнгән. Аның кызлары шәһәргә дан китергәннәр. Анна һәм Мария хатын — кызлар гимназиясен бишлегә генә укып чыкканнар. Анна шәһәрдә укыту эшен алып барган, ә соңыннан гәзитнең редакциясендә эшләгән. Кече кызы Мария Самарада институтта укып чыгып, Мәскәүдә укуын һәм фәнни эшен башкарган. Ул археология, антик сәнгатен өйрәнергә тырышкан, экспедицияләрдә казу эшләрен оештырган, йөздән артык мәкалә басып чыгарган. Ул Советлар Союзының фәнни Академиясенең вәкиле булып торган. Бөтен тормышын фән өйрәнүенә багышлаган, кияүгә дә чыкмаган. Үзенең туйга дип теккән күлмәген, хатын — кызлар куллана торган әйберләрен Богырыслан музеена васыять иткән. Алар әле дә музейда саклана.

Богырыслан шәһәре тарихының бер үзенчәлеге бар. Богырыслан туганнан алып ике гасыр буенча ул төрле административ бүлемнәргә бирелә. 19 — нчы гасырның башында киредән Ырынбур губерниясенә кайтарыла, ә 1851 ел башыннан Самара губерниясенә урнаша, 1928 елда Урта — Идел өлкәсендә, ә 1929 елда Урта — Идел краенда Богырыслан округы дип санала. 1934 елда яңадан Ырынбур өлкәсендә әлегә кадәр район шәһәре булып тора.

Бу алыш — биреш шәһәрнең тормышына зарар китерсә дә, файдасы да күренгәли. Самара өлкәсендә булганга, 1888 елда Богырыслан аша тимер юл үтә. Шәһәр үсә бирә, ул зур шәһәрләр белән элемтәгә, сәүдә эшләренә катышырга ярдәм бирә. Бу Самара — Златоуст тимер юлы талантлы инженер Н.Г.Гарин — Михайловский планы буенча аның җитәкчелегендә салына. Ул инженер гына түгел, күренекле язучы да була. Шушы тимер юлы салынганда ул Богырыслан уездының Гундоровка дигән авылында тора. Усадьбасында яңача хуҗалыкны алып бармакчы була, әммә дошманнары аның хуҗалыгы алга киткәнен күреп, көнчелек белән өйләренә, амбарларына ут төрткәннәр. Гундоровкада "Берничә ел авылда" дигән очеркы туа. Биредә үк "Теманың балачагы", "Гимназистлар" дигән повестьлары языла.